КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 7 декабрь г.Казань № 953

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында» 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-891 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 12 февраль, 38 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 31 август, 746 нчы; 2013 ел, 14 март, 160 нчы; 2013 ел, 29 август, 611 нче; 2014 ел, 28 март, 194 нче; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2015 ел, 21 октябрь, 789 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1001 нче; 2016 ел, 7 октябрь, 725 нче; 2017 ел, 15 август, 581 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Урман хуҗалыгы министрлыгы хезмәткәрләренең чик санын вазыйфаи окладлар буенча федераль бюджет (субвенция) акчасы исәбеннән хезмәт өчен түләүнең 317,2 мең сум айлык фонды белән 61 берәмлек итеп;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта «, табигатьтән файдалану» сүзен төшереп калдырырга;

2.1 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

3.1 пунктның икенче, дүртенче – алтынчы абзацлары үз көчен югалткан дип санарга;

3.2 пунктта:

унөченче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

егерменче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01);

республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәүенә алу (02.04.03).»;

3.3 пунктта:

3.3.1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дәүләт милкендә булган җирләрдән җир кишәрлеген булдырганда территориянең кадастр планында җир кишәрлеген урнаштыру схемасын килештерә;

дәүләт кадастр исәбенә кую турында гаризалар бирә, шул исәптән җир кишәрлекләре чикләрен тәгаеләгәндә һәм (яки) урман фонды җирләре составындагы урман кишәрлекләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алганда.»;

3.3.3 һәм 3.3.4 пунктчалар үз көчен югалткан дип санарга;

5.5 пунктның өченче абзацында «, төбәк әһәмиятендәге аерым сакланыла торган табигый территорияләрне оештыру һәм саклау өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин